


Олылыр айлыгында кvбрәк чәчләренә чал кунган кешеләр турында сойлибез. «РМ Инсар районы буенча социаль яклау» каршындагы пенсионерлар очен кондезге тору бvлегендә матурлык, зирәклек һәм сәләт бәйрәме узган. Биредә «Комеш яшь патшабикәсе» конкурсында ин стильле, ин креатив һәм ин сойкемле катнашучыны сайлаганнар.

Чара йомгаклары буенча жюри дипломнар тапшырган. «Ин сойкемле» номинациясендә беренчелекне Адилә Исмаил кызы Брюзгина яулаган. «Ин креатив» дип Анна Михайловна Петрова аталган. Ә «Ин стильле» исеме белән Александра Викторовна Курдюкованы котлаганнар.

- Конкурста оч гvзәл зат катнашты, - ди «РМ Инсар районы буенча социаль яклау» оешмасынын житәкчесе Светлана Владимировна Анисимова. - Комеш яшьтәге ханымнарнын барысы да алдан тәкъдим ителгән биремнәргә яхшы әзерләнгәннәр. Әйтеп китим, безнен оешма «Старшее поколение» Федераль проектнын «Демография» милли проекты нигезендә 2021 елда Инсар белән Кадошкино районнары авылларынын 65 яшьтәге һәм аннан олылары, инвалидлар очен оештырылды. Биредә алар иртәнге 9 сәгатьтән алып 13 сәгатькә кадәр саулыкларын ныгыталар, вакытларын кvнелле һәм файдалы vткәрәләр. Аларны ике автобусыбыз тvләvсез яшәгән урыннарыннан барып ала, ойләренә илтеп куя.

